**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлегенең Чүрчил авылында**

**«9» нче декабрь 2019 ел** **№6**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлегенең Чүрчил авылы гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлегенең Чүрчил авылында 2020 елда, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, 1 һәм 2 группа инвалидларыннан, күп балалы гаиләләрдән кала, Чүрчил авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшүсмердән 500,00 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Торак пункт эчендәге юлны ремонтлау өчен вак таш сатып алу.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокук порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Яшел Үзән муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга, шулай ук Олы Карагуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Олы Карагуҗа авылы, Күпер урамы, 23 йорт (мәдәният йорты бинасы), Чүрчил авылы, Тау асты урамы, 26 йорт (мәдәният йорты бинасы).

**Гражданнар җыенында рәислек итүче** **М.Р. Минһаҗев**

**Олы Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы, Совет Рәисе** **М.Р. Минһаҗев**